**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ОЛЫ АЧАСЫР АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

# КАРАР

2022 елның 26 сентябре №99

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының Олы Ачасыр авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Олы Ачасыр авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгының хезмәткә түләү күләмнәрен, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Олы Ачасыр авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфа окладларын билгеләү турында»гы 2020 елның 30 нчы сентябрендәге 8 нче номерлы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында

«Татарстан Республикасында үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы муниципаль берәмлекләр башлыкларының, муниципаль берәмлекләр башлыклары урынбасарларының, депутатларның, җирле үзидарәнең сайланулы органнары әгъзаларының, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең, рәис урынбасарларының, аудиторларының һәм муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфа окладларын айлык акчалата бүләкләү күләмнәрен арттыру турында»гы 2022 елның 22 августындагы 881 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Карары нигезендә Олы Ачасыр авыл җирлеге Советы **карар итте:**

1. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының Олы Ачасыр авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Олы Ачасыр авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгының хезмәткә түләү күләмнәрен, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Олы Ачасыр авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфа окладларын билгеләү турында»гы 2020 елның 30 нчы сентябрендәге 8 нче номерлы карарына (алга таба – Карар) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1). 1 пунктта:

1.1) беренче абзацта «2020 елның 1 октябреннән» сүзләрен «2022 елның 1 октябреннән» сүзләренә алмаштырырга;

1.2) икенче абзацта «15 759 күләмендә (унбиш мең җиде йөз илле тугыз) һәм айлык 8 826 сум (сигез мең сигез йөз егерме алты) сум күләмендә акчалата бүләк» сүзләрен «16 390 (уналты мең өч йөз туксан сум) һәм ай саен 9 180 сум күләмендә акчалата бүләк (тугыз мең бер йөз сиксән) сум» сүзләренә алмаштырырга;

2). 2 пунктта:

2.1) беренче абзацта «2020 елның 1 октябреннән» сүзләрен «2022 елның 1 октябреннән» сүзләренә алмаштырырга;

2.2) икенче абзацта «15 759 (унбиш мең җиде йөз илле тугыз) сум» сүзләрен «16 390 (уналты мең өч йөз туксан) сум күләмендә» сүзләренә алмаштырырга;

3) 3 пунктта «2020 елның 1 октябреннән» сүзләрен «2022 елның 1 октябреннән» сүзләренә алмаштырырга;

4) «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Олы Ачасыр авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфа окладлары күләмнәре» кушымтасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Олы Ачасыр авыл җирлеге Советының
2022 елның 26 сентябрендәге
№ 99 нчы карарына кушымта

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ «ОЛЫ АЧАСЫР АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ» МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕНДӘ МУНИЦИПАЛЬ ХЕЗМӘТКӘРЛӘРНЕҢ ВАЗЫЙФА ОКЛАДЛАРЫ КҮЛӘМНӘРЕ

| **Муниципаль хезмәт вазыйфалары исемнәре** | **хезмәт хакының айлык күләме, сум** |
|---|---|
| Олы Ачасыр авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары (сәркәтибе) | 15 905 |

2. Әлеге карарны Интернет челтәренең Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре составындагы Зеленодольск муниципаль районы мәгълүмат сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru), шулай ук мәгълүмат стендларында: Олы Ачасыр авылы, Үзәк урамы, 46 йорт (җирлек хакимияте бинасы), Олы Ачасыр авылы, Кооператив урамы, 26 йорт (авыл мәдәният йорты бинасы) урнаштырырга.

**Олы Ачасыр авыл жирлеге**
**башлыгы урынбасары, Совет рәисе** **М.Г. Гатиятуллин**